Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Ошторма-Юмья авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР

«02»февраль, 2026 ел № 2

2026 елга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасын эшләү кагыйдәләрен раслау һәм контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ошторма-Юмья авыл җирлеге территориясендә иминлек өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның «11» июньдаге 25 номерлы карары нигезендә Ошторма-Юмья авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ошторма-Юмья авыл җирлегендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл жирлеге башлыгы С.В. Тимофеев

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге башкарма комитетының 2026 елның «02» февральдаге 2 номерлы карарына кушымта

2026 елга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ошторма-Юмья авыл җирлегендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасы

ПАСПОРТ

| Программаның исеме | 2026 елга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ошторма-Юмья авыл җирлегендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасы |
|---|---|
| 2026 елга программаны эшләүнең хокукый нигезләре | «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасын эшләү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары |
| Программаны эшләүче | Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаның максатлары | - төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү;<br>- контрольдә тотыла торган субъектларның мәҗбүри таләпләрне намуслы үтәвен стимуллаштыру;<br>- төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган гамәлдәге һәм потенциаль шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;<br>- төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль буенча чаралар үткәргәндә контроль-күзәтчелек эшчәнлеге системасының ачыклыгын арттыру |
| Программаның бурычлары | - профилактик чараларның төрләре, формалары һәм интенсивлыгының контроль астындагы конкрет субъектларның (объектларның) үзенчәлекләренә һәм аларга бирелгән куркыныч дәрәҗәсенә (хәвефлелек классына) бәйлелеген билгеләү һәм бәяләү, әлеге факторларны исәпкә алып, |

| | |
|---|---|
| | профилактик чаралар үткәрү;<br>- закон белән саклана торган кыйммәтләргә һәм мәҗбүри таләпләрне бозуга зыян салуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, аларның барлыкка килү куркынычын бетерү яисә киметү ысулларын билгеләү;<br>- контрольдә тотылучы субъектларның хокукый грамоталылык дәрәҗәсен күтәрү, шул исәптән мәҗбүри таләпләр һәм аларны үтәү буенча кирәкле чаралар турында мәгълүматның һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү юлы белән;<br>- контрольдә тотылучы затларга контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге чыгымнарын һәм административ йөкләнешне киметү |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2026 ел |
| Финанслау чыганаклары | Программаны гамәлгә ашыру Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге башкарма комитеты эшчәнлеген агымдагы финанслау кысаларында гамәлгә ашырыла |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | - Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын киметү;<br>- законнарны үтәүче контрольдә тотылучы субъектларның өлешен арттыру;<br>- контроль (күзәтчелек) органының профилактика чаралары системасын үстерү;<br>- контроль-күзәтчелек органы эчендә профилактик эш технологияләрен эшләү һәм гамәлгә кертү;<br>- контроль-күзәтчелек органы эшчәнлегенең үтә күренмәлелеген арттыру;<br>- контрольдәге субъектларның хокукый грамоталылык дәрәҗәсен күтәрү;<br>- контрольдәге субъектларның үзләрен намуслы тотарга мотивацияләү;<br>- контрольдәге органнарга административ йөкләнешне киметү;<br>- Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авылы җирлеге территориясендә тикшерүләр оештыру һәм уздыру юлы белән ачыкланган закон таләпләрен бозуларның гомуми санын киметү |
| Программаның структурасы | Программа ярдәмче программаларны гамәлгә ашыруны күздә тотмый |

## 1. Контроль төрен гамәлгә ашыруның агымдагы торышына анализ

Юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең һәм гражданнарның төзекләндерү өлкәсендә норматив хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәве муниципаль контроль предметы булып тора.

Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнар тарафыннан закон бозуларны кисәтү һәм булдырмау максатларында төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында мәгълүмат Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырылган.

Контрольдәге өлкәдә хәлне яхшыртуга контроль астындагы субъектларның җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә мәгълүмат җиткерү дәрәҗәсен арттыру, шулай ук мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча үз вакытында чаралар күрү ярдәм итәргә мөмкин.

## 2. Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасын гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары

Программаны гамәлгә ашыруның максатлары:

- төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль буенча чаралар үткәргәндә контроль-күзәтчелек эшчәнлеге системасының ачыклыгын арттыру

юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең законнарның мәҗбүри таләпләрен бозуларын кисәтү;

- хокук бозулар куркынычын профилактикалау инфраструктурасын булдыру;

- төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль өлкәсендәге законнарның мәҗбүри таләпләрен бозуга китерә торган гамәлдәге һәм потенциаль шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;

- контрольдәге субъектларга административ йөкләнешне киметү; юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, гражданнарның социаль җаваплы, намуслы, хокукый тәртипле моделен формалаштыру.

Профилактик чаралар үткәрү түбәндәге бурычларны хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк.

- мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, аларның барлыкка килү куркынычын бетерү яисә киметү ысулларын билгеләү;

- профилактик чараларның төрләре, формалары һәм интенсивлыгының контроль астындагы конкрет субъектларның (объектларның) үзенчәлекләренә һәм аларга бирелгән куркыныч дәрәҗәсенең (хәвефлелек классының), әлеге факторларны исәпкә алып профилактик чаралар үткәрүгә бәйлелеген билгеләү һәм бәяләү;

- профилактика эшен оештыру өчен кирәкле статистик белешмәләрнең төрләре һәм җыелмалары исемлеген билгеләү;

- контрольдәге субъектларга административ йөкләнешне киметү;

юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, гражданнарның социаль җаваплы, намуслы, хокукый тәртипле моделен формалаштыру.

3. Профилактика чаралары исемлеге,
аларны үткәрү сроклары (ешлыгы)

| № | Чара формасы | Җаваплы затлар | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Контрольдә тотыла торган субъектлар белән аларга мәгълүмат бирү максатларында гавами чаралар (җыелышлар, киңәшмәләр, семинарлар) үткәрү юлы белән мәгълүмат бирү | Тимофеев С.В. – авыл җирлеге башлыгы | 2026 ел дәвамында |
| 2 | Төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча белешмәләрнең рәсми сайтында урнаштыру рәвешендә мәгълүмат бирү | Тимофеев С.В. – авыл җирлеге башлыгы | 2026 ел дәвамында |
| 3 | Төзекләндерү өлкәсендә хокук куллану практикасын гомумиләштерү һәм анализлау, мәҗбүри таләпләрне типик бозулар килеп чыгу сәбәпләрен классификацияләү һәм хокук куллану практикасы турында расланган докладны Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру | Тимофеев С.В. – авыл җирлеге башлыгы | Ел саен 25 февральдән дә соңга калмыйча |
| 4 | Контрольдә тотылучы затларга мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү чараларын күрү максатларында кисәтүләр игълан итү | Тимофеев С.В. – авыл җирлеге башлыгы | 2026 ел дәвамында |
| 5 | Контроль (күзәтчелек) органы вазыйфаи затларының төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү мәсьәләләре буенча шәхсән, телефон элемтәсе, электрон почта аша; язма сорату алганда — «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" Федераль законда билгеләнгән тәртиптә язма рәвештә, шулай ук профилактик чаралар үткәрү барышында консультацияләр үткәрүе | Тимофеев С.В. – авыл җирлеге башлыгы | 2026 ел дәвамында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 | Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында профилактик визит | Тимофеев С.В. – авыл җирлеге башлыгы | 2026 ел дәвамында |

6. Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасының нәтиҗәлелеге һәм эффектлылыгы күрсәткечләре

Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре:

- контрольдәге субъектларның белем дәрәҗәсен арттыру;
- законнарны үтәүче контрольдә тотылучы субъектларның өлешен арттыру;
- контроль-күзәтчелек органының профилактика чаралары системасын үстерү;
- Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге территориясендә хокук бозуларны кисәтү буенча профилактика эшенең нәтиҗәлелеген арттыру,
- җирлек территориясендә тикшерүләр оештыру һәм үткәрү юлы белән ачыкланган Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозуларның гомуми санын киметү.